БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

5 июнь 2025 ел № 329

**Балтач район Советының 2013 елның 30 маендагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 165 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2014 елның 27 мартындагы 217 номерлы, 2016 елның 19 мартындагы 32 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 229 номерлы редакциядә)**

Балтач муниципаль районы җирлекләре җирле үзидарә органнары эшенең нәтиҗәлелеген объектив бәяләү, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Балтач район Советының 2013 елның 30 маендагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 165 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнары эшчәнлеген мониторинглау турында Нигезләмәгә (2014 елның 27 мартындагы 217 номерлы, 2016 елның 19 мартындагы 32 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 229 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлекләренә район җирлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү һәм аларны бүләкләү максатларында грантлар бүлеп бирү тәртибенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Грантлар район бюджетыннан субсидия рәвешендә - беренче урын өчен - 100,0 мең сум, икенче урын өчен - 75,0 мең сум, 3 урын өчен - 50,0 мең сум бүлеп бирелә. Грант суммаларының 50%ын җирлекләрнең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә премия бирүгә һәм 50%ын җирлекләр территориясен үстерүгә тоту рөхсәт ителә.».

2. Җирле үзидарә көнендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлеге күрсәткечләренең иң

яхшы казанышларына ирешкән өчен ел йомгаклары буенча җиңүчеләрне бүләкләүгә тәкъдим итәргә.

3. Район җирлекләре башлыкларына һәм структура бүлек башлыкларына 2025 елның беренче июленә кадәр Балтач муниципаль районы җирлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген мониторинглауның гамәлдәге күрсәткечләренә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү өчен тәкъдимнәр бирергә.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (http://baltasi.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин